**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

КАРАР

от 16.01.2020

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№ ПГ-1

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру буенча комиссия төзү турында**

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау турында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 22 ноябрендәге УП-598 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 11 июлендәге «Татарстан Республикасы территориясендә хәрби вакытта һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру буенча комиссия төзү турында» 473 номерлы карары белән, шулай ук Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда, хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә халыкның исән калуы өчен кирәкле оешмаларның тотрыклы эшләвен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башлыгы **карар бирә**:

1. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә оешмаларның сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә тотрыклылыгын арттыру буенча Комиссия төзергә.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә һәм аның составындагы сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе турындагы Нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 3 нче кушымта нигезендә, Актаныш муниципаль районы территориясендә икътисадның тотрыклы эшчәнлеге һәм халыкның исән калуы өчен кирәкле объектлар Исемлеген расларга.

4. Актаныш муниципаль районы Башлыгы карары үз көчен югалткан дип санарга: «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә оешмаларның сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә тотрыклы эшләвен арттыру буенча комиссия төзү турында" 2019 елның 23 гыйнварындагы ПГ-4 номерлы карары;

5. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм хокукый мәгълүмати порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Муниципаль район Башлыгы Э. Н. Фаттахов

Актаныш муниципаль районы
башлыгы карарына
«16» 01 2020 ел.№ ПГ-1
1 нче санлы кушымта

Актаныш муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклылыгын арттыру буенча
Комиссия составы

| | |
|---|---|
| 1. Габдулхаев И. И. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе - Комиссия рәисе |
| 2. Гарипов Р. И. | Татарстан Республикасы Актаныш районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Комиссия рәисе урынбасары |
| 3. Нурлыева Л. Ф. | Татарстан Республикасы Актаныш районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Комиссия рәисе урынбасары |
| 4. Шәрифҗанов И. И. | "ТР буенча 15 ОФПС" ФГКУ 103 нче ПСЧ начальнигы - комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| 5. Мирзашарипова О. М. | Татарстан Республикасы Актаныш районы башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге начальнигы - Комиссия секретаре |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| 6. Хуҗахметова Г. Ф. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Актаныш муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге начальнигы-социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча төркем җитәкчесе (килешү буенча) |
| 7. Хәернасов Р. Ф. | Актаныш РУЭСы начальнигы - идарә, элемтә һәм хәбәр итү системалары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе (килешү буенча) |
| 8. Шакиров А. З. | "Актаныш автотранспорт хуҗалыгы" МУП директоры - транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе (килешү буенча) |

житәкчесе (килешү буенча)

10. Мирхәйдәров А. А. Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы - агросәнәгать комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме житәкчесе (килешү буенча).

Актаныш муниципаль районы
башлыгы карарына
“16” 01 2020 ел № ПГ-1
2 нче санлы кушымта

**Сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә Актаныш муниципаль районы территориясендә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе турында**

**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе турында әлеге Нигезләмә Актаныш муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясенең (алга таба - Комиссия) статусын һәм эшчәнлек тәртибен билгели.

1.2. Комиссия Актаныш муниципаль районы (алга таба – оешмалар) оешмаларының хәрби конфликтлар вакытында яки шул конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр аркасында халыкны исән калдыру өчен кирәкле эшчәнлеген тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү максатларында оештырыла.

1.3. Комиссия сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклылыгын арттыру чараларын планлаштыруны һәм үтәүне тәэмин итүче даими эшләүче орган булып тора.

1.4. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм күрсәтмәләренә, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.5. Комиссия составы Татарстан Республикасы Актаныш район башкарма комитетының җитәкче составы һәм килешү буенча җәлеп ителә торган федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары вәкилләреннән төзелә.

## 2. Комиссия бурычы

2.1. Комиссиянең төп бурычы - хәрби конфликтлар вакытында яки бу конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халыкның исән калуы өчен кирәкле оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру чараларын планлаштыру һәм үтәүне оештыру:

торак пунктларны, икътисад һәм инфраструктура объектларын, шулай ук гражданнар оборонасының инженер-техник чаралары таләпләренә туры китереп җитештерү чараларын рациональ урнаштыру;

яный торган чорда комплекслы маскировка үткәрү;

энергия һәм су белән тәэмин итү системаларының һәм чыганакларының эшләвенең ышанычлылыгын арттыру;

башка кичектергесез эшләрне планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү;

җитештерү процессын торгызу өчен кирәкле матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын алдан ук булдыру;

документациянең иминият фонды булдыру;

заманча зарарлану чаралары тәэсирендә җитештерү фондларын саклау нәтиҗәлелеген арттыру.

## 3. Комиссия функцияләре

3.1. Комиссия үзенә йөкләнгән бурыч нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

хәрби вакыт шартларында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру буенча чараларны планлаштыру һәм үткәрү;

оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру мәсьәләләре буенча тикшеренү эшләре үткәрү;

сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә аларның тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны оешмалар тарафыннан гамәлгә ашыруны бәяләү;

сугыш вакыты һәм гадәттән тыш хәлләр шартларында оешмаларның тотрыклылыгын күтәрүгә, оешма һәм халык персоналын яклауга һәм аларны Татарстан Республикасы Актаныш районы башкарма комитетына тапшыруга юнәлтелгән тәкъдимнәр эшләү;

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында оешмаларның тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның үтәлешен анализлау, шул исәптән вазыйфаи затларны һәм җитәкчеләрне тыңлау юлы белән;

җыеннарда, өйрәнүләрдә, күнегүләрдә һәм башка план чараларында катнашу.

3.2. Ягулык-энергетика комплексы, сәнәгать җитештерүе тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә:

гадәттән тыш хәлләрдә һәм сугыш чоры шартларында электр һәм җылылык белән тәэмин итү, су һәм ягулык белән тәэмин итү элементларының һәм системаларының тотрыклылыгы дәрәҗәсен билгеләү;

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә оешмаларның энергия белән тәэмин итүнең автоном чыганакларыннан эшләү мөмкинлекләрен анализлау;

сәнәгать предприятиеләре эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны үтәүнең нәтиҗәлелеген бәяләү;

предприятиеләрнең төп җитештерү фондларын һәм җитештерү куәтләрен югалтуларны мөмкин булган дәрәҗәдә бәяләү;

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә ягулык-энергетика комплексы, сәнәгать җитештерүе тотрыклылыгын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

3.3. Торак-коммуналь хуҗалык эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә:

торак-коммуналь хуҗалык эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чаралар үтәлешенең нәтиҗәлелеген анализлау;

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә торак-коммуналь хуҗалыкның тотрыклылыгын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

3.4. Транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә:

транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны үтәүнең нәтиҗәлелеген анализлау;

транспорт чараларын һәм транспорт коммуникацияләрен һәм корылмаларын җимерүнең мөмкин булган югалтуларын билгеләү;

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә транспорт системасының тотрыклы эшләвен арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

3.5. Агросәнәгать комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә:

терлекчелектә, үсемлекчелектә һәм азык-төлек продуктларын һәм азык чималын җитештерүдә зыяннарны киметү буенча чараларны үтәүнең нәтиҗәлелеген анализлау;

һәм халыкка хезмәт күрсәтү күләмен билгеләү;

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә агросәнәгать комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

3.6. Социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә:

социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру чараларын үтәүнең нәтиҗәлелеген анализлау;

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

3.7. Идарә, элемтә һәм хәбәр итү системаларының тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә:

идарә, элемтә һәм хәбәр итү системаларының тотрыклылыгын арттыру чараларын үтәүнең нәтиҗәлелеген , шул исәптән идарәнең төп органнары белән элемтә бозылганда идарә итүче оешмалар белән өзлексез идарә итүне тәэмин итү сәләтен анализлау;

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының барлык дәрәҗәдәге идарә органнары һәм халкының җитәкче составына хәбәр итү системасының әзерлеген анализлау;

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районына идарә, элемтә һәм хәбәр итү системаларының тотрыклылыгын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

3.8. Үзенә йөкләнгән вазыйфаларны башкару максатларында Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан һәм оешмалардан комиссиягә йөкләнгән бурычларны һәм функцияләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматларны соратып алырга;

оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру мәсьәләләрен карауда катнашуга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары вәкилләрен, кызыксынган оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр белгечләрен билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә;

оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә тикшеренүләр эшләүне һәм уздыруны башлап җибәрергә һәм үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча эшләнгән чараларны гамәлгә ашыруның максатчанлыгын карарга;

оешмаларның тотрыклылыгын арттыру өлкәсендә тикшеренүләр үткәрүдә катнашу;

оешмаларның җитәкчеләрен һәм вазыйфаи затларын оешмаларның тотрыклылыгын арттыру мәсьәләләре буенча тыңларга, Комиссия утырышларын үткәрергә.

## 4. Комиссия эшен оештыру

4.1. Комиссия составына комиссия рәисе, рәис урынбасарлары, секретаре һәм әгъзалары керә.

4.2. Комиссия рәисе Комиссия эшен оештыру һәм комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җавап бирә.

Комиссия рәисе бурычлы:

Комиссиянең планлы һәм планнан тыш утырышларын үткәрү;

сугыш вакыты шартларында һәм гадәттән тыш хәлләрдә, аларны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының икътисадый үсеше һәм гражданнар оборонасы планнары проектларына кертү һәм халыкны яклау өчен оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләүне оештырырга;

Татарстан Республикасы күрше муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм оешмалар төзи торган сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның эшчәнлегендә тотрыклылыкны арттыру комиссиясе белән үзара

планлаштырырга һәм оештырырга.

4.3. Комиссия рәисе урынбасарлары бурычлы:

рәис булмаганда аның вазыйфаларын башкарырга;

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә сугыш чоры шартларында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклылыгын арттыру чараларын планлаштыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча комиссия һәм аның эш төркемнәре эшен оештыру;

комиссия рәисе карарларын һәм күрсәтмәләрен үтәүне контрольдә тоту.

4.4. Комиссия секретаре бурычлы:

киләсе елга Комиссиянең эш планын килештерүне әзерләргә һәм оештырырга;

комиссия утырышларын оештырырга;

комиссия әгъзаларына һәм аның утырышына чакырылган затларга комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында, утырышның көн тәртибен күрсәтеп хәбәр итәргә;

комиссия әгъзаларына хәбәр итү һәм җыю буенча өйрәнүләр үткәрергә;

утырыш беркетмәләрен алып барырга һәм аларның нәтиҗәләре буенча карарлар рәсмиләштерергә;

комиссия карарларын башкаручыларга җиткерүне оештырырга һәм аларның үтәлешен контрольдә тотарга;

комиссия рәисе һәм аның урынбасарының аерым күрсәтмәләрен үтәргә;

комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итәргә.

4.5. Комиссия утырышлары комиссия рәисе раслаган эш планы нигезендә елга бер тапкырдан да ким үткәрелми. Комиссия секретаре комиссия утырышы беркетмәсен алып бара, анда аның карарларын һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен терки. Комиссия утырышы беркетмәсенә комиссия рәисе һәм секретаре кул куя.

4.6. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы була.

4.7. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы башкара.

## 5. Комиссиянең эш төркемнәре

5.1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә оешмаларның сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның үтәлешен турыдан-туры планлаштыру, гамәлгә ашыру һәм тикшереп тору өчен комиссия тарафыннан эш төркемнәре оештырыла:

ягулык-энергетика комплексы һәм сәнәгать җитештерүе тотрыклылыгын арттыру буенча;

торак-коммуналь хуҗалык эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча;

транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча;

агросәнәгать комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча;

социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча;

идарә, элемтә һәм хәбәр итү системаларының тотрыклы эшләвен арттыру буенча.

5.2. Эшче төркемнәр составы килешү буенча җәлеп ителә торган җирле үзидарә органы, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләреннән төзелә һәм комиссия рәисе тарафыннан расланa.

5.3. Ягулык-энергетика комплексының һәм сәнәгать җитештерүенең тотрыклылыгын арттыру төркеме түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

ягулык-энергетика комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру чараларын фаразлау һәм планлаштыру;

ягулык-энергетика комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның нәтиҗәлелеген анализлау;

ягулык-энергетика комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгы дәрәҗәсен билгеләү;

ягулык-энергетика комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба үстерү

сәнәгать предприятиеләре эшенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның нәтиҗәлелеген бәяләү;

бу предприятиеләрнең төп җитештерү фондларын һәм җитештерү куәтләрен югалтуларны анализлау;

сәнәгать предприятиеләре эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба үстерү, җитештерү көчләрен урнаштыруны яхшырту һәм район территориясендә хуҗалык элемтәләренең ышанычлылыгын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

5.4. Торак-коммуналь хуҗалык эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

торак-коммуналь хуҗалык эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру чараларын фаразлау һәм планлаштыру;

торак-коммуналь хуҗалык эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның нәтиҗәлелеген анализлау;

торак-коммуналь хуҗалык эшчәнлегенең тотрыклылыгы дәрәҗәсен билгеләү;

торак-коммуналь хуҗалык эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

5.5. Транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме гамәлгә ашыра:

транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру чараларын фаразлау һәм планлаштыру;

транспортның барлык төрләре эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның нәтиҗәлелеген анализлау;

транспорт чараларының һәм транспорт объектларының һәм корылмаларның (ремонт предприятиеләренең, күперләрнең, кичүләрнең) җимерелү ихтималын билгеләү;

транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

5.6. Агросәнәгать комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме гамәлгә ашыра:

авыл хуҗалыгы комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру чараларын фаразлау һәм планлаштыру;

терлекчелектә, үсемлекчелектә һәм азык-төлек продуктларын һәм азык чималын җитештерүдә зыяннарны киметү буенча чараларның нәтиҗәлелеген анализлау;

авыл хуҗалыгы комплексының егәрлекләрен югалтуларны билгеләү, продукция җитештерү күләмен киметү һәм халыкка хезмәт күрсәтү.

5.7. Социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме гамәлгә ашыра:

социаль өлкә объектлары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру чараларын фаразлау һәм планлаштыру;

социаль өлкә объектлары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның нәтиҗәлелеген анализлау;

социаль өлкә объектларының тотрыклылыгы дәрәҗәсен билгеләү;

социаль өлкә объектлары эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

5.8. Идарә, элемтә һәм хәбәр итү системалары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча төркем гамәлгә ашыра:

идарә, элемтә һәм хәбәр итү системалары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру чараларын фаразлау һәм планлаштыру;

идарә һәм элемтә системасының тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның нәтиҗәлелеген, шул исәптән дублерларның район оешмалары белән идарәнең төп органнары белән элемтә бозылганда идарә итүне тәэмин итү сәләтен анализлау;

идарә, элемтә һәм хәбәр итү системалары эшчәнлегенең тотрыклылыгы дәрәҗәсен билгеләү;

буйсынудагы һәм югарыдагы идарә органнары белән идарә һәм элемтә системалары эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба үстерү буенча тәкъдимнәр

комиссиянең еллык планын эшләүдә катнашу;

комиссия рәисе һәм аның урынбасарларының аерым күрсәтмәләрен үтәү;

эш төркеменә йөкләнгән бурычлар һәм функцияләр чикләрендә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны үтәүнең нәтиҗәлелеген анализлауны уздыруны оештыру;

эш төркеменә йөкләнгән бурычлар һәм функцияләр чикләрендә оешмаларның тотрыклылыгын алга таба үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләүне оештырырга.

5.10. Эшче төркемнәрнең эш тәртибе һәм планнары аларның җитәкчеләре тарафыннан Комиссия эше планы нигезендә раслана.

Актаныш муниципаль районы башлыгы
карарына «16» 01 2020 ел № ПГ-1
3 нче санлы кушымта

Актаныш муниципаль районы территориясендә икътисадның тотрыклы эшләве
һәм халыкның исән калуы өчен кирәкле объектлар исемлеге

| ЭО атамасы | ЭО җитәкчесе фамилиясе | Эш телефоны | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| Актаныш РУЭС Яр Чаллы «Таттелеком» ААҖ Яр Чаллы ЗУЭС | Хаернасов Ренат Фәрит улы | 3-04-04 | |
| Түбән Кама электр челтәрләре, Актаныш РЭСы | Шакиров Марат Марсель улы | 5-12-54 | |
| "Теплосервис" ҖЧҖ | Нәгыймов Дилфат Мисхәт улы | 3-28-92 | |
| Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе | Харисов Дәниф Әсрар улы | 3-09-08 | |
| "Татавтодор" ААҖ филиалының Актаныш ДРСУ | Идрисов Ришат Илшат улы | 3-28-70 | |
| "Актаныш РҮХ " ДАССУ | Хаев Айдар Рәфкать улы | 3-09-38 | |
| "Әлмәтгаз " ЭПУ РГЭСы | Әмирҗанов Рөстәм Мәзһәр улы | 3-15-50 | |
| Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы ДКУнең Актаныш участок урманчылыгы | Әхмәтгалиев Әгъзап Хәмдегали улы | 89510626185 | |
| "Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге" ФФБУЗ Чаллы шәһәрендә, Актаныш районында | Хафизова Зәмфирә Зиннур кызы | 3-00-26 | |
| "ТР буенча 15 ОФПС" ФГКУ 103 ПСЧ | Шәрифҗанов Илназ Илдус улы | 3-09-49 | |
| Актаныш районы буенча Россия ЭЭМ бүлеге | Хәйретдинов Илшат Илфир улы | 3-14-01 | |